ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.10.2025 г. Казань № 252-3/э-2025

«РТЮ» ААҖ филиалы – Трансэнерго структур бүлекчәсе – Энергия белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясе һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.11.2024 ел, № 314-2/э-2024 карары белән билгеләнгән озак сроклы аерым тарифларга 2026 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (куллану) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә кирәкле тулай табышны озак сроклы индексацияләү алымын кулланып билгеләнә торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау хакында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 22.10.2025 ел, № 20-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендәге челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә озак сроклы индивидуаль тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай табышына 2026 ел өчен төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «РТЮ» ААҖ филиалы – Трансэнерго структур бүлекчәсе – Энергия белән тәэмин итү

буенча Горький дирекциясе һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә 2025-2029 елларга аерым тарифлар билгеләү турында» 13.11.2024 ел, № 314-2/э-2024 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В.Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.11.2024 ел, № 314-2/э-2024
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
22.10.2025 № 252-3/э-2025
карары редакциясендә)

2025 елның 1 гыйнварыннан башлап 2029 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә «РТЮ» ААҖ филиалы – Трансэнерго структур бүлекчәсе – Энергия белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясе һәм «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә календарь буенча бүленгән индивидуаль тарифлар

| т/с | Челтәр оешмасының исеме | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «РТЮ» ААҖ филиалы – Трансэнерго структур бүлекчәсе – Энергия белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясе – «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте | 2025 | 287 680,83 | 88,38 | 0,94317 | 287 680,83 | 88,38 | 0,94317 |
| | | 2026 | 361 572,94 | 105,96 | 1,17856 | 361 572,94 | 105,96 | 1,17856 |
| | | 2027 | 311 155,58 | 95,59 | 1,02014 | 311 155,58 | 95,59 | 1,02014 |
| | | 2028 | 323 601,80 | 99,42 | 1,06094 | 323 601,80 | 99,42 | 1,06094 |
| | | 2029 | 336 545,88 | 103,39 | 1,10338 | 336 545,88 | 103,39 | 1,10338 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.11.2024 ел, № 314-2/э-2024
карарына 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
22.10.2025 № 252-3/э-2025
карары редакциясендә)

«РТЮ» ААҖ филиалы – Трансэнерго структур бүлекчәсе – Энергия белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясенең 2025-2029 елларга (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча) кирәкле тулай кереме

| т/с | Татарстан Республикасы челтәр оешмасының исеме | Ел | Югалтуларны исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының кирәкле тулай табышы |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1. | Энергия белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясе – Трансэнергоның структур бүлекчәсе – «РТЮ» ААҖ филиалы | 2025 | 92 497,44 |
| | | 2026 | 118 231,69 |
| | | 2027 | 100 045,23 |
| | | 2028 | 104 047,04 |
| | | 2029 | 108 208,92 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге